# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге составына керүче «Пятилетка» совхоз торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 3 «18» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең «Пятилетка» совхоз торак пунктында 2023 елның «18» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенен “Пятилетка” совхозы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- "Пятилетка" совхозы торак пунктында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- “Пятилетка” совхозы торак пунктында чишмәне төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- "Пятилетка" совхозы торак пунктында юлларны кардан чистарту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 301 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 197 кеше, 65,4 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 197 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка” совхоз торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка” совхоз торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенен “Пятилетка” совхозы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- "Пятилетка"совхозы торак пунктында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- "Пятилетка” совхозы торак пунктында чишмәне төзекләндерү (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- "Пятилетка"совхозы торак пунктында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Отарка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.И.Фазылов